КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь г.Казань № 1113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характер-дагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2016 ел, 3 октябрь, 710 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2016 ел, 3 октябрь, 710 нчы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрның беренче урынбасары (халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге мәсьәләләрен алып баручы)»;

дүртенче абзацта «баш белгеч» сүзләрен «әйдәп баручы киңәшче» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин